ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

07.10.2020 д. Канаш - №2

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Канаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 23 октябренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Канаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы:

- 941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Канаш авылы, Центральная урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков